ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 г. Заинск № 538

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкару чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, пассажирлар ташучыларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1212 нче карарына (23.07.2018) үзгәрешләр кертү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131нче федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, башкарма комитет

**карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкару чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, пассажирлар ташучыларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.3.1 пунктынының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

“ пассажирлар ташучылар әлеге документның 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларда хокукый актлар, башка норматив актлар яки муниципаль хокук актлары нигезендә субсидия бирү планлаштырылган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан средстволар алмаска тиеш”.

1.2. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“3.2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты пассажирлар ташучылар белән финанс органы билгеләгән тиешле форма нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы тиешле бюджетыннан субсидия бирү турында Килешү төзи (алга таба – килешү)”.

2. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Карарны билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А.Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**